СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

28.11.2023　　　　с.Ямбулатово　　　　№ 39 – 205

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96_6 һәм 220_1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының үтәлеш үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәнең 22 статьясындагы 3 пункты, 25 статьясындагы 3 пунктының гамәлдә булуын туктатып торырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Ямбулат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет-финанс һәм икътисадый мәсьәләләр буенча Ямбулат авыл җирлегенең даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе урынбасары,
ТР, Югары Ослан муниципаль районының
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы урынбасары　　　　М.Н.Ахметзянов